Тукай муниципаль районы Шилнәбаш авыл җирлеге Шилнәбаш авылы

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

«13» ноябрь, 2020 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Шилнәбаш авылы гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «2021 елда яшәү урыны буенча Шилнәбаш авыл җирлеге Шилнәбаш авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 (биш йөз илле) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

1) Шилнәбаш авыл җирлегендә Бөек Ватан сугышында һәлак булган сугышчылар истәлегенә куелган һәйкәлне төзекләндерү;

2) янгын депосын газлаштыру;

3) Шилнәбаш авылының Мәктәп урамы буенча яңгыр канализациясе урнаштыру;

4) юлларга вак таш җәю, чокырларны ямау»

2. Тукай муниципаль районы Шилнәбаш авыл җирлеге Шилнәбаш авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

3. Тукай муниципаль районы Шилнәбаш авыл җирлеге Шилнәбаш авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Шилнәбаш авыл җирлеге Башлыгы О.А. Гончарова